| «РАССМОТРЕНО» | «СОГЛАСОВАНО» | «УТВЕРЖДАЮ» |
|---|---|---|
| на заседании ШМО нач.кл. | Зам. директора по УВР | Директор МБОУ «Минняровская ООШ» |
| __________Ф.А.Басирова | __________ А. И. Гиздатуллина | __________ И.Х.Исхаков |
| Протокол № 1 | «27» 08 2020г. | Приказ №107 |
| от «26» августа» 2020г | | «___»__________2020г. |

**Рабочая программа**
**по родному (татарскому) языку для 1 класса**
Гиздатуллиной Айсылу Ильгизовны,
учителя начальных классов
МБОУ «Минняровская основная общеобразовательная школа»
Актанышского муниципального района
Республики Татарстан

2020-2021 учебный год

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

| Бүлек исеме | Предмет нәтиҗәләре | | Метапредмет нәтиҗәләр | Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|
| | Укучы өйрәнәчәк | Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак | | |
| Әлифбагача чор | -язуга карата төп гигиена кагыйдәләрен үтәү;<br>-язма хәрефләрнең барлык элементларын да алгоритм буенча яки тактлап дөрес яза белү.<br>элементар образлы күзаллау дәрәҗәсендә тел берәмлекләре: сүз, җөмлә, текстны **аңлый**, шулай ук татар алфавитының басма һәм язма хәрефләр системасын **атый һәм формалары буенча аера белү**;.<br>-рәсем, график модель яки тиешле фишкалар кулланып, беренчедән, дәрестә тудырылган тел ситуацияләре буенча 2 — 4 сүздән торган **җөмләләр** һәм 3 — 4 җөмләдән торган **хикәя төзү**; икенчедән, парта артында **дөрес утыру** һәм язма әсбаплардан дөрес **файдалану**, алгоритм буенча яки тактлап язма хәрефләрнең барлык элементларын да **дөрес яза белү** | -татар алфавитының басма һәм язма хәрефләр системасын атый һәм формалары буенча аера белү. | **Регулятив күнекмә:**<br>-үзконтроль нигезләрен яхшы белү, уку һәм танып-белү процессында үзбәя, карар кабул итүне аңлы рәвештә сайлый белү: бер-берең не тикшерү процессында үзеңнең, башкаларның уку һәм танып-белү эшчәнлеген күзәтә, анализлый белү; уку ситуацияләрендә карар кабул итә белү һәм җаваплылык хисе тою.<br>таблица буенча кагыйдәнең дөреслеген тикшерегә;<br>гамәлләрне таләп ителгән вакытта башларга һәм тәмамларга;<br>кагыйдә, инструкцияләрне истә тотарга һәм шуларга ияреп гамәлләр кылырга;<br>максатка кагылышсыз гамәлләрдән тыелырга;<br>сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләр урнаштырырга.<br><br>**Танып-белү күнекмәсе:**<br>-төшенчәләрне билгели, йомгаклый, аналогияләрне таба, сәбәп-нәтиҗә элемтәләрен урнаштыра, логик фикерләү күнекмәләре: мөһим | - үзеңне милләтеңнең вәкиле итеп тану;<br><br>- мотивация нигезендә белем алу һәм танып белүнең укучыларның үзлегеннән үсеш, үзлегеннән укып белем алуга әзерлек;<br><br>-шәхси сайлау нигезендә мораль (әхлакый) проблемаларны чишүдә компетентлык, үз гамәлләреңә аңлы һәм җаваплы караш формалаштыру;<br><br>-укуга җаваплы караш формалаштыру;<br><br>-башка кешегә, аның уй-фикеренә хөрмәтле һәм игелекле караш булдыру;<br><br>-бердәм башкарыла торган эшчәнлеккә уңай караш тудыру;<br><br>-башка шәхескә хөрмәт тудыру;<br><br>-үзеңдә лидерлык |
| Әлифба чоры | -авазларның сузык, ягъни җырлана торган аваз һәм тартык, ягъни җырланмый торган;әйткәндә, сөйләм органнарында киртә ясала / ясалмый торган авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә булуын; тартыкларның нечкә- калын яңгырашын сузык аваз хәрефләре белдерүен;<br>сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бөтенлегенә ия булуын;сүзнең иҗекләргә бүленүен, бер иҗекнең көчлерәк һәм озынрак әйтелүен;сөйләм авазлары язуда шартлы график символлар (түгәрәк, квадрат) яки хәрефләр белән белдерелүен белү;<br>- авазларга характеристика бирү;<br>- анализ вакытында тартыкларның яңгырау- | -укырга – язарга өйрәтү барышында гамәли алынган белемнәрне, эш осталыгын һәм күнекмәләрне гомумиләштерү,систем алаштыру. | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | саңгыраулыгын билгеләү<br>алымнарын **куллану;**<br>- сүзне иҗекләргә **бүлү**;<br>- схемалардан сүзнең аваз язылышын иҗекләп һәм орфоэпик **дөрес итеп уку**;<br>- элемент-шаблоннар нигезендә басма һәм язма хәрефләрне **төзү һәм анализлау;**<br>- билгеле бер алгоритм буенча хәрәкәт элементлары нигезендә хәрефләр **язу;**<br>- иҗекләрдә һәм сүзләрдә тоташтыруның өч алымын **үтәү;**<br>- тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген **йомшарту;**<br>- күчереп язганда һәм диктант вакытларында җөмләләрне һәм үз исемнәрен **дөрес язу;**<br>- бизәк-бордюрлар **ясый ала белү**. | | һәм аннан бәйле сүзләрдән торган логик чылбыр төзү;<br>-ике яки берничә предметның, күренешнең гомуми билгесен табу, аларның охшашлыгын аңлату;<br>-сүзлекләр, башка эзләнү схемаларын актив куллана белү сәләтен мотивлаштыруны үстерү: кирәкле мөһим эзләнә торган сүзләрне билгеләү; эзләү нәтиҗәләрен үз эшчәнлегең белән чагыштырып карау.<br>мөһим бәйләнешләрне аерып чыгару нигезендә кагыйдә формалаштырырга;<br>күнегүләрне мөстәкыйл эшләү алымнарын үзләштерергә;<br>тәкъдим ителгән план буенча телдән аңлатырга;<br>материаль объект, таблица, рәсем, схемалар, сүзлекләр кулланырга;<br>бирелгән алгоритм буенча күнегүләр башкарырга;<br>фикерләүдә логик чылбыр төзергә;<br>уку мәсьәләләрен модельләштерүдә билгеләр (символлар) кулланырга.<br><br>**Коммуникатив күнекмә:**<br>-Укытучы һәм яшьтәшләре | сыйфатларын тормышка ашыру ысулларын формалаштыру. |
| Әлифбадан соңгы чор | -туган телнең сөйләм төзелешен **аңлау**, аваз, иҗек, сүз, сүтезмә, җөмлә, текст кебек тел берәмлекләрен образлы **күзаллау**;<br>- татар алфавиты басма һәм<br>язма **хәрефләренең график системасын**, һәр хәрефнең элемент **формаларын,** дөрес утыру һәм язма әсбапларны куллану **кагыйдәләрен белү.**<br>**- О,ө**<br>хәрефләрен беренче иҗектә генә **язу;**<br>- хәрефләрне язуда тоташ һәм тиз итеп язу алымнарын **тормышка ашыру**. | -тизләтелгән темпта язу шартларында график грамоталылыкны һәм каллиграфик сыйфатны формалаштыру. | | |
| **Татар теле**<br><br>Фонетика, орфоэпия һәм графика | -аваз һәм хәрефләрне аеру;<br>-ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчелекләрен аңлау, авазларга характеристика бирә алу;<br>-хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм, кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны куллана алу. | -сүзгә басым куйганда яки сүзнең дөрес әйтелешендә икеләнү туган очракта укытучысына һәм әти-әнисенә мөрәҗәгать итә алу. | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Лексикология | -мәгънәсе ачыклану таләпителә торган сүзләрне табу. | - текстларда кабатлаулар булдырмас өчен тәкъдим ителгән сүзләр арасыннан тиешлесен сайлап алу. | белән бердәм эшчәнлекне оештыра, индивидуаль һәм төркемдә эшли белү күнекмәсе булдыру. Дәлилле итеп үз фикерен башкаларга җиткерә белү**:** бердәм эшчәнлектә мөмкин булган рольләрне билгели белү; | |
| Синтаксис | -җөмлә һәм сүзләрне аерырга өйрәнү. | -җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аеру. | | |
| морфология | - предметны, билгене, хәрәкәтне белдерүче сүзләрне аеру. | | бердәм эшчәнлектә билгеле бер рольне башкара белү; әңгәмәдәшченең позициясен аңлау һәм кабул итә белү; төркемдә уку эшчәнлеген оештыра белү (гомуми максатлар билгели белү, рольләрне бүлешү, бер-берең белән уртак фикергә килү.<br>-үз хисләреңне, фикерләреңне бирү, үз эшчәнлегеңне планлаштыру;<br>язма һәм телдән, монологик һәм контекст сөйләм төрләрен оста файдалана белү**:** коммуникация бурычларын билгели белү һәм аңа туры килгән сөйләм чараларын сайлап ала белү; башка кешеләр белән коммуникация барышында сөйләм чараларын сайлап ала һәм куллана белү (парлы диалог, кече төркемдә); диалог барышында үз фикереңне дәлилләп бирә, партнер фикерен сорый белү. | |
| Орфография һәм пунктуация | -дөрес язылыш кагыйдәләрен өйрәнгән күләмдә куллану. | - орфографик хата ясау мөмкинлеге булган очракларны аңлау, хаталар өстендә эшләгәндә, аларның сәбәпләренә төшенү һәм алдагы язма эшләрдә хата җибәрмәү юлларын ачыклау. | | |
| Сөйләм үстерү | -аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайлау;<br>-көндәлек аралашуга бәйле татарча сөйләм әдәбе формаларын дөрес куллану.<br><br>укытучы яки укучы укыган текстны аңлау;<br>сүзләрдәге үзенчәлекле авазларны дөрес итеп әйтү;<br>аваз-хәреф анализы ясау, авазларның һәм хәрефләрнең туры килү-килмәвен әйтү;<br>текстны бәйләнешсез җөмләләрдән аеру;<br>текстны кисәкләргә бүлү һәм аларга исем бирү;<br>текстның тулы эчтәлеген сөйләү;<br>текст исеменең мәгънәсен аңлау, бирелгән вариантлардан дөресен сайлап алу;<br>аңлап, сүзләрне тутырып, сәнгатьле һәм дөрес | -тәкъдим ителгән исемнең эчтәлегенә туры килгән текст төзү, бирелгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү. | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | итеп уку;<br>сүзләрне, җөмләләрне, текстны укытучы укыганнан соң дөрес итеп язу һәм дөреслеген тикшерү;<br>рәсем буенча телдән хикәя төзү;<br>программада караган теоретик мәгълүматны белү. | | партадаш күрше белән яисә төркемдә хезмәттәшлек итәргә;<br>нинди дә булса предмет яисә объектка төрле карашлар булу мөмкинлеген аңларга;<br>килешергә һәм уртак эшчәнлектә гомуми чишелешкә килергә;<br>сораулар формалаштырырга. | |

**Укыту курсы темаларының эчтәлеге**

| Бүлек исеме | Кыскача эчтәлек | Сәгать саны |
|---|---|---|
| Әлифбагача чор | Язарга әзерләнү.Дәфтәр юллары белән танышу.Туры һәм ыргаклы туры сызыклар. Озын туры сызык, астан элмәкле туры сызыклар һәм аларны тоташтыру. Юл хәрефе элементларын яздыру. Элмәкле туры сызыклар Хәреф элементларын яздыру. Овал һәм и, у хәреф элементларын язу.<br>Укырга-язарга өйрәтү барышында гамәли алынган белемнәрне, эш осталыгын һәм күнекмәләрне гомумиләштерү, системалаштыру һәм ныгыту. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, язганда, иҗекләп, юлдан юлга күчерү. | 6 |
| Әлифба чоры | Язу күнекмәләрен шомарту. Язуга карата төп гигиена кагыйдәләрен үтәү. Хәрефләрнең график яктан дөрес язылышын, сүздә аларны тоташтыру ысулларын ныгыту. Хәрефләрне дөрес тоташтырып, ритмлап иҗекләр, сүзләр һәм кечкенә җөмләләр язу.<br>Кечкенә текстларны тактадан, дәреслектән дөрес итеп (иҗек һәм хәрефләрне төшереп калдырмый, урыннарын алмаштырмый, хәреф формаларын бозмый), сүзләп күчереп язу. Әйтелеше белән язылышы туры килгән сүзләрдән төзелгән җөмләләрне ишетеп язу.<br>Язганда тиешле гигиена таләпләрен үтәү, кул һәм бармак мускулларының җитез һәм ритмик хәрәкәт итүләренә ирешү.<br>Барлык баш һәм юл хәрефләренең язылышы һәм аларның тоташтыруның төп сызыклары белән таныштыру һәм каллиграфик дөрес язарга өйрәтү.Авазларны сүздә тиешле язма хәрефләр белән күрсәтү.Сүздәге хәрефләрне, аларны тоташтырган сузыкларын өзмичә ритмик язуны(ас-өс) булдыру, дәфтәр юлларына хәрефләрне һәм сүзләрне, тигез ара калдырып, тигез, дөрес урнаштыру.Башта укытучы белән иҗек –аваз анализы ясаганнан соң, тора бара мөстәкыйль рәвештә сүзләр, җөмләләр язу.<br>Башта язмача, аннары басмача үрнәкләрдән сүзләр, җөмләләр күчереп язу. Үрнәк текст белән чагыштырып карау һәм сүзләрне иҗекләп орфографик уку ярдәмендә дәфтәргә язылганнарның дөреслеген тикшерү.<br>Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүзләрне, шундый өч-дүрт сүздән торган җөмләләрне әйтеп яздыру.<br>Дөрес күчереп язу алымнарын һәм эзлеклелеген үзләштерү. Сүзләр арасында буш урын калдыру, юлдан-юлга күчерү | 54 |

| | | |
|---|---|---|
| | билгесе кую кебек график чараларның функциясен аңлау. | |
| Әлифбадан соңгы чор | Өйрәнелгән хәрефләрне төркемләп язу күнекмәләрен башкару, тактлап һәм тизләтелгән темпта язу. Хәрефләрне тоташтыруның өч төрен ныгыту. Язудагы җитешсезлекләр өстендә эшләү. | 3 |
| Татар теле<br><br><br><br>Фонетика, орфоэпия һәм графика | Авазлар. Әйтелгән сүздән аерым сузык яки тартык авазны ишетеп, аерып алу. Сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны аеру.<br>Иҗек. Иҗек калыплары. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, сүз басымын билгеләү.<br>Хәреф һәм аваз турында төшенчә, аларны аеру. Әйтелгән сүздән аерым сузык яки тартык авазны ишетеп, аерып алу. Сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны, нечкә һәм калын тартык авазларны, парлы һәм парсыз тартык авазларны, яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны аеру. Яңгырау авазларны аеру, аларның парларын билгеләү. Авазга өйрәнелгән күләмдә характеристика бирү: сузык-тартык; басымлы-басымсыз; калын-нечкә, яңгырау-саңгырау, парлы яки парсыз тартык. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Авазларның хәзерге әдәби тел нормаларына туры килгән әйтелеше.<br>Язуда **ъ** һәм **ь** хәрефләрен куллану. **Е – ё**, **ю**, **я** хәрефләре булган сүзләрдә аваз һәм хәреф бәйләнешен билгеләү. Сүзләр арасында буш урын калдыру, юлдан-юлга күчерү билгесе кую, кызыл юл кебек график чараларны куллану. Алфавиттагы хәрефләрнең исемен дөрес әйтү, аларның урнашу тәртибен белү. Сүзлекләр яки белешмәлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана белү. | 36<br><br><br><br>17 |
| Синтаксис | Предмет атамасын белдергән сүзләр-исемнәр белән танышу. Исем, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Ялгызлык исемнәрне таба белү. Кем? Нәрсә? сорауларына җавап биргән исемнәрне аеру. Исемнәр янында кулланыла торган сүзләр-бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән таныштыру.<br>Предметның билгесен белдергән сүзләр белән танышу. Сыйфат, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы.<br>Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр белән танышу.Фигыль. Мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. | 3 |
| морфология | Сүз һәм аның лексик мәгънәсе. Сүз һәм җөмләне аеру. Җөмлә белән эш: аерым сүзләрне табу, аларның урнашу тәртибен үзгәртү.<br>Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аеру, аларның охшаш һәм аермалы якларын аңлау. | 5 |
| Орфография һәм пунктуация | Дөрес язу кагыйдәләре һәм аларның кулланылышы белән танышу:<br>сүзләрнең аерым язылуы; **о**, **ө** хәрефләренең татар сүзләренең беренче иҗегендә генә язылуы;җөмлә башындагы беренче сүзне һәм ялгызлык исемнәрне баш хәреф белән язу, җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләрен дөрес кую;сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм юлдан-юлга иҗекләп дөрес күчерү. | 6 |
| Сөйләм үстерү | Укылган текстның эчтәлеген үзлегеңнән кычкырып укыганда яки тыңлаганда аңлау. Сюжетлы рәсемнәр, үзеңнең уеннарың, күзәтүләрең буенча хикәяләү характерындагы зур булмаган текстлар төзү.<br>Аралашу ситуациясен – аралашу кем белән, кайда, нинди максат белән башкарылуын аңлау. Үз фикереңне әйтү һәм аны дәлилләү. Әңгәмә үткәрүнең төп күнекмәләрен үзләштерү (сүз башлау, әңгәмәгә кушылу, аны дәвам итү, игътибарны җәлеп итү һ.б.). Уку, көндәлек аралашу шартларында тел әдәбе нормаларын үзләштерү (сәламләү, хушлашу, гафу үтенү, рәхмәтле булу, сорау белән мөрәҗәгать итү). | 4 |
| | | **99** |